**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МОРДОВСКО-АФОНКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

423103, Мордовское Афонькино село, Цаплина ул., 19 дом

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
**МОРДВА АФОНЬКӘСЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423103, Мордва Афонькэсе авылы, Цаплин урамы, 19нче йорт

тел. (84396) 3-48-29, факс: (84396) 3-48-49, email: Mord.Cmn2@tatar.ru:

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**26 июнь 2020 ел** **№ 9**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Мордва Афонькәсе авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 29 гыйнварындагы 61 номерлы «2020 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында» карары, «Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Мордва Афонькәсе авыл җирлеге Башкарма комитеты **карар бирә:**

1. 2020 елның 1 июленнән Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Мордва Афонькәсе авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә 6124,86 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга : www.pravo.tatarstan.ru, махсус мәгълүмат стендларында, шулай ук Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Мордва Афонькәсе авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе А.И.Митяев

1 нче кушымта
Татарстан Республикасы Чирмешән
муниципаль районы Мордва Афонькәсе
авыл җирлеге
Башкарма комитеты
карарына
26 июнь 2020 ел, № 9

**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Мордва Афонькәсе авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлегенең бәясе 2020 елның 1 июленнән**

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе (сум.) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2228,52 |
| 3. Мәрхүмнең гәүдәсен (җәсәдләрен) зиратка илтү | 1020,83 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2875,51 |
| **БАРЛЫГЫ** | **6124,86** |

2 нче кушымта
Татарстан Республикасы Чирмешән
муниципаль районы Мордва Афонькәсе
авыл җирлеге
Башкарма комитеты
карарына
26 июнь 2020 ел, № 9

**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы
Мордва Афонькәсе авыл җирлегендә
җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлегенең бәясе
2020 елның 1 июленнән**

| **Хезмәт күрсәтү атамасы** | **Хезмәт күрсәтү бәясе (сум.)** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Кәфенләү | 232,12 |
| 3. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 1996,40 |
| 4. Мәрхүмнең гәүдәсен (җәсәдләрен) зиратка илтү | 1020,83 |
| 5. Җирләү (каберләрне казу һәм күмү) | 2875,51 |
| **БАРЛЫГЫ** | **6124,86** |